ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» март 2020 ел № 79

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә җәмәгать эшләрен оештыру турында

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җәмәгать эшләрен оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1997 елның 14 июлендәге 875 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «2020 елга халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итүнең территориаль программаларын эшләү һәм килештерү турында» 2020 елның 04 февралендәге 64 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елда Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районы территориясендә, теркәлгән 80 эшсез гражданны эшкә урнаштыруга җәлеп итеп, кушымтадагы үткәрелә торган төп иҗтимагый эш төрләре исемлеген расларга.
2. Менделеевск районы ЦЗН» ДКУ филиалы белән берлектә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә оештырыла торган иҗтимагый эшләр күләмен, эшсез халык санын һәм составын исәпкә алып, конкрет территориянең социаль инфраструктурасын үстерү зарурлыгыннан чыгып билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарларына кураторлык итүче юнәлешләр буенча җәмәгать эшләрен оештыру тәртибе һәм әлеге эшләрдә катнашу шартлары турында мәшгуль булмаган халыкка мәгълүмат бирү эшен оештырырга.
4. Әгерҗе муниципаль районының авыл җирлекләре башлыкларына һәм оешма, предприятие, учреждениеләрнең эш бирүчеләренә «Менделеевск районы ЦЗН» ДКУ филиалына җәмәгать эшләрен оештыруда ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.
5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://agryz.tatarstan.ru.

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А Баженовага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.С. Авдеев**

Расланган
Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
03 март 2020 ел, № 79
карары белән

**2020 елда Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районы территориясендә, теркәлгән 80 эшсез гражданны эшкә урнаштыруга җәлеп итеп, үткәрелә торган төп иҗтимагый эш төрләре исемлеге**

1. Юллар төзү һәм төзекләндерү, юл полотносын ремонтлау һәм төзү эшләре, юл төзелеше өлкәсендә башка эшләр башкару.
2. Газ, канализация һәм башка коммуникацияләр салганда булышчы һәм ярдәмче эшләр, тапшырыла торган объектларны төзекләндерү, җир эшләре, иске кирпеч диварларын сүтү һәм төзелеш өлкәсендә башка эшләр.
3. Авыл хуҗалыгында сугару эшләрен башкару, территорияләрне төзекләндерү, терлек азыгы, печән әзерләү, агач кисү, авыл хуҗалыгы продукциясен әзерләү, саклау һәм эшкәртү һәм авыл хуҗалыгы өлкәсендә башка эшләр башкару.
4. Куаклар, агачлар кисү, үлән чабу, территорияне чүп-чардан чистарту, чүп-чар чыгару, яшелләндерү, үсентеләр утырту һәм урман хуҗалыгында башка эшләр.
5. Тарихи-архитектура һәйкәлләрен, ял зоналарын, мәдәният паркларын, скверларны торгызу һәм саклау: яшелләндерү, утырту, су үткәрү, чәчәк түтәлләрен су сибү, агач кисү, куак кисү һәм җыештыру, үләнне чабу, иске йортлар территориясен җыештыру, аларны төзекләндерү, яшелләндерү һәм чистарту, квартал эчендәге территорияләрне һәм контейнер мәйданчыкларын чүп-чардан һәм көнкүреш калдыкларыннан чистарту һәм башка эшләр.
6. Автобус тукталышларын төзекләндерү һәм җыештыру, төяү-бушату эшләре, элемтә хезмәтләре белән тәэмин итү, сезонлы эшләр (товарлар ташу, кар чистарту һ.б.), транспорт һәм элемтә өлкәсендә башка эшләр.
7. Базар территориясен төзекләндерү, халыкны сәүдә, җәмәгать туклануы һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре белән тәэмин итү, йөк ташу, кафе, ашханә биналарын җыештыру һәм сәүдә һәм җәмәгать туклануы өлкәсендә башка эшләр.
8. Мәдәният учреждениеләрендә, хезмәт һәм ял лагерьларында балаларның ялын оештыру, биналарга хезмәт күрсәтү, балигъ булмаганнарның җәйге хезмәтен оештыру, җәйге чорда балалар мәйданчыкларында эшләү һәм мәгариф, мәдәният, сәнгать һәм фән өлкәсендә башка эшләр.
9. Икенчел чималны һәм калдыкларны җыю һәм эшкәртүне оештыру, территорияләрне җыештыру, төзекләндерү һәм яшелләндерү, биналарга, корылмаларга хезмәт күрсәтү, ремонтлау эшләре һәм сәнәгать өлкәсендә башка эшләр.
10. 10. Территорияләрне яшелләндерү һәм төзекләндерү, урман-парк хуҗалыгын, ял һәм туризм зоналарын үстерү, биналарга хезмәт күрсәтү һәм ремонт ясау, халыкка социаль ярдәм күрсәтү (бакчалар казу, утын әзерләү,

фатирларны косметик ремонтлау һ. б.), спорт лагерьларында балаларның ялын оештыру һәм сәламәтлек саклау, физик культура һәм социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә башка эшләр.

11. «Татарстан Республикасында җәмәгать эшләрен оештыру турында» 2009 елның 24 февралендәге 99 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән башка эшләр.